ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.02 2021 ел № 115

«Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 16 августындагы 551 номерлы карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Татарстан Республикасының Спас муниципаль районы Советының 2007 елның 27 декабрендәге 23-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында социаль ипотека программасы буенча торак сатып алуга мохтаҗларны кичектергесез ярдәм итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының №23-2 (22.10.2020 № 2-12 үзгәрешләр белән) карары нигезендә 08.02.2021 6-2, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегия беркетмәсен үтәү өчен 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы бурычлары буенча, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 16 августындагы 551 номерлы карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Регламентның 2.6. пунктын түбәндәге эчтәлекле 9 пунктча өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә.».

1.2. Регламентның 2.9 пунктын түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә:

«8) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Р.Р. Закировага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин